# Иярчен кушма җөмләләр (Сложноподчинённые предложения)

**Түбәндәге җөмләләрнең баш һәм иярчен җөмләләрен табыгыз. Бәйләүче чараларын аңлатыгыз. Җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез. Схемаларын ясагыз.**

Үрнәк:

*1)Кем эшләми, 2)шул ашамый.*

*( Икенче җөмлә -баш җөмлә, беренче җөмлә- иярчен җөмлә. Иярчен җөмлә баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр (кем, шул) белән бәйләнгән.*

***(кем...), [ шул...].***

***1)Без кабызган утлар сүнмәс алар.***

***2)Кыш җиткәч, балалар чаңгыга чыктылар.***

***3)Син нәрсә куштың, мин шуны эшләдем.***

| **Аналитик чаралар:**<br>**1)подчинительные союзы и союзные слова- ияртүче теркәгечләр, теркәгеч сүзләр: чөнки, әгәр, гәрчә, гүя, әйтерсең, диярсең;**<br>**2) мөнәсәбәтле сүзләр: шул, шул вакытта, шундый, шуңа, алайса;**<br>**3) аныклау һәм көттерү интонациясе ( интонация ожидания и пояснения)** | **Синтетик чаралар:**<br>**1)кушымчалар –ча/-чә, -лы/-ле, -дай/-дәй һ.б.;**<br>**2) бәйлек һәм бәйлек сүзләр (послелоги и послеложные слова): белән, кебек, шикелле, төсле, хәтле, кадәр, чаклы, сәбәпле һ.б.;**<br>**3) янәшә килү ( примыкание)** |
|---|---|
| *1.Урамда шундый җылы, **гүя** яз җиткән. (На улице так тепло, **словно** наступила весна.)*<br>*2. **Әгәр** синең бергә булсак, без җиңәрбез.(Если будем с тобой вместе, **то** победим.)*<br>*3.**Кайчан** яз җитте, **шунда** кошлар кайтты. (Наступила весна, **тогда** прилетели птицы.)*<br>*4.**Кем** эшләми, **шул** ашамый.(**Кто** не работает, **тот** не ест.)*<br>*5.Мин беләм: ул җиңәчәк. (Я знаю: он победит.)* | *1.Син әйткәнне мин эшләдем. (То, что ты сказал, я сделал.)*<br>*2. Дусты бар кеше бәхетле. (Счастлив человек, кто имеет друга.)*<br>*3. Без китәсе поезд соңга кала. (Поезд, на котором мы должны уехать, опаздывает.)*<br>*4. Ул килгәнче, без табын әзерләдек. (До того как он пришел, мы накрыли стол.)*<br>*5. Көз җитү белән, агачлар саргайды. (Как только наступила осень, деревья пожелтели.)* |

Күнегүләр эшләп, белемнәрегезне ныгытыгыз!

2 нче күнегү ( 69 бит)

3 нче күнегү

4 нче күнегү

Өй эше: 5 нче күнегү (69 бит).

Баш җөмләләр өстәп язарга.